**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О единовременной денежной выплате членам семей военнослужащих и лиц, проходивших службу в войсках национальной гвардии Российской Федерации, погибших (умерших) в результате участия в специальной военной операции, проводимой на территориях Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики и Украины»**

В целях материальной поддержки членов семей граждан, добровольно выполнявших военные задачи в ходе специальной военной операции, проводимой на территориях Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики и Украины с 24 февраля 2022 года, погибших (умерших) в результате участия в указанной специальной военной операции, **постановляю:**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 4 апреля 2022 года № УП-233 «О единовременной денежной выплате членам семей военнослужащих и лиц, проходивших службу в войсках национальной гвардии Российской Федерации, погибших (умерших) в результате участия в специальной военной операции, проводимой на территориях Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики и Украины» следующие изменения:

а) дополнить новым пунктом 5 следующего содержания:

«5. Распространить действие настоящего Указа на членов семей граждан, добровольно выполнявших военные задачи в ходе специальной военной операции, проводимой на территориях Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики и Украины с 24 февраля 2022 года, погибших (умерших) в результате участия в указанной специальной военной операции.»;

б) пункт 5 считать пунктом 6.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
07 июня 2022 года
№ УП-400

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

2022 елның 24 февраленнән Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә ирекле рәвештә хәрби бурыч үтәгән, әлеге махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2022 елның 4 апрелендәге ПУ-233 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа 5 нче пункт өстәргә:

«5. Әлеге Указның гамәле даирәсенә 2022 елның 24 февраленнән Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә ирекле рәвештә хәрби бурыч үтәгән, әлеге махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларын кертергә.»;

б) 5 нче пунктны 6 нчы пункт дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аның үтәлешен тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 07 июнь
№ ПУ-400